Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Табар-Черкене авыл җирлеге Советының 2022 елның 5 июленнән 62 номерлы «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының «Табар-Черкене авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләүне уздыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» карары

«Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 15 июнендәге 1081 номерлы карарының 2 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Табар-Черкене авыл җирлеге Советы карар итте:

1) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын муниципаль программаларга кертү муниципаль программалар максатларыннан һәм (яисә) муниципаль программаларга карамаган муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый сәясәте максатларыннан чыгып гамәлгә ашырыла.»;

2) 12 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының муниципаль программаларга карамый торган муниципаль программалар максатларына һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый сәясәте максатларына туры килүе;»;

3) 12 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ташламаларга түләүчеләр тарафыннан бирелгән ташламаларга ихтыяҗ булу, ул ташламаларга хокуктан файдаланучы түләүчеләр санының һәм ташламалар куллануга потенциаль хокукка ия түләүчеләр санының 5 еллык чорга нисбәте белән характерлана.».

2.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Табар-Черкене авыл
җирлеге башлыгы,
Табар-Черкене авыл җирлеге
Советы рәисе И.Х.Ибатуллин